КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 май г.Казань № 392

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасының норматив хокук актларын һәм муниципаль хокук актларын кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуын оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасының норматив хокук актларын һәм муниципаль хокук актларын кабул иткәндә һәм тормышка ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуын оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 22 февраль, 87 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләренә алыштырырга, «һәм җирле үзидарә органнарының», «һәм муниципаль хокук актларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктта «башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләренә алыштырырга, «һәм муниципаль хокук актларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәген» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Үзәк)» сүзләренә алыштырырга, «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләренә алыштырырга, «һәм муниципаль хокук актларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче пунктта «башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

5 нче пунктта:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенә» сүзләрен «Үзәгенә» сүзенә алыштырырга;

дүртенче һәм бишенче абзацларда тиешле килешләрдәге һәм саннардагы «министрлыклары һәм ведомстволары» сүзләрен тиешле килешләрдәге һәм саннардагы «башкарма хакимиятенең республика органнары» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы пунктта «министрлыклары һәм ведомстволарына» сүзләрен – «башкарма хакимиятенең республика органнарына» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенә» сүзләрен «Үзәгенә» сүзенә алыштырырга;

7 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары сайтларында» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Үзәкнең рәсми сайтларында» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ нче пункт өстәргә:

«$7^1$. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына карарлар кабул иткәндә һәм муниципаль хокук актларын эшләгәндә агымдагы елга гамәлдә булган Гавами өстенлекләр реестрын исәпкә алуны тәкъдим итәргә.»;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасының норматив хокук актларын һәм муниципаль хокук актларын кабул иткәндә һәм тормышка ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуын оештыру тәртибе турындагы нигезләмәдә:

исемендә «башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләренә алыштырырга, «һәм җирле үзидарә органнарының», «һәм муниципаль хокук актларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

1.2 нче пунктта тиешле килешләрдәге һәм саннардагы «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен тиешле килешләрдә һәм саннарда «дәүләт хакимияте

башкарма органнары» сүзләренә алыштырырга, «һәм җирле үзидарә органнарының», «һәм муниципаль хокук актларын», «һәм җирле үзидарә органнарын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 нче пунктта:

дүртенче абзацта «бәяләү критериясен» сүзләрен «бәясен» сүзенә алыштырырга;

бишенче абзацта «һәм Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләре » сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләренә алыштырырга, «, җирле үзидарә органнары», «, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче абзацта «һәм муниципаль хокук актларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гавами өстенлекләр реестры – социологик тикшеренүләрдә катнашкан халыкның гомуми санында өстенлекне билгеләгән халык өлешен һәм гавами өстенлекләрне гамәлгә ашыру дәрәҗәсен бәяләргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүматны үз эченә алган актуаль гавами өстенлекләр исемлеге.»;

1.4 нче пунктта:

өченче абзацта «һәм муниципаль хокук актларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турындагы җәмәгатьчелек фикерен тикшерүне»;

2.1 нче пунктта «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган җәмәгатьчелек фикерен социологик тикшеренүләрне үткәрү планы нигезендә үткәрелә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 нче һәм 2.3 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Җәмәгатьчелек фикеренә социологик тикшеренүләр үткәрүне оештыру «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан конкурс нигезендә социологик тикшеренүләрне гамәлгә ашыручы теләсә кайсы милек рәвешендәге оешмаларны җәлеп итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Җәмәгатьчелек фикеренә социологик тикшеренүләр үткәргәндә гражданнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылмаска тиеш. Гражданнарның җәмәгатьчелек фикеренә социологик тикшеренүләр үткәрүдә катнашуы ирекле характерга ия.»;

2.5 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

2.6 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» сүзләрен «Үзәк» сүзенә алыштырырга;

2.7 нче пунктта «һәм Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы президиумы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.8 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

2.9 нчы пунктта «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләренә алыштырырга, «һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.10 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге тарафыннан» сүзләрен «Үзәк тарафыннан» сүзләренә алыштырырга;

3.1 нче һәм 3.2 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Иҗтимагый экспертиза үткәрү өчен хокук актлары проектлары Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасына җибәрелә.

3.2. Хокук актлары проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы бәяләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары коллегияләрендә мәҗбүри каралырга тиеш.»;

3.3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

4 бүлек исемендә «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләренә алыштырырга, «һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 нче һәм 4.2 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының гавами өстенлекләрне тормышка ашыру нәтиҗәлелеге социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре нигезендә бәяләнә.

4.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан гавами өстенлекләрне тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү этабында җәмәгатьчелек фикеренә социологик тикшеренүләр үткәрү нәтиҗәсе булып хокук актларын тормышка ашыруны дәвам итү, аларга төзәтмәләр кертү, аларны туктатып тору яки туктатуны максатка ярашлы булуны бәяләү тора.»;

4.3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

5 бүлек үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин